КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июль г.Казань № 575

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 декабрь, 997 нче; 2015 ел, 17 апрель, 260 нчы; 2015 ел, 9 сентябрь, 659 нчы; 2015 ел, 8 октябрь, 753 нче; 2016 ел, 14 март, 139 нчы; 2016 ел, 26 октябрь, 785 нче; 2017 ел, 8 май, 264 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 763 нче; 2017 ел, 20 октябрь, 799 нчы; 2018 ел, 4 май, 316 нчы; 2018 ел, 8 август, 647 нче; 2019 ел, 21 гыйнвар, 29 нчы; 2019 ел, 15 апрель, 291 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2022» саннарына алыштырырга;

1 нче пунктта «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2022» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2022» саннарына алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлында «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2022» саннарына алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2022» саннарына алыштырырга;

«Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләм-нәре | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 343 577,13 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 31 487,6 мең сум;<br>2015 елда – 30 987,08 мең сум;<br>2016 елда – 32 137,9 мең сум;<br>2017 елда – 56 504,6 мең сум;<br>2018 елда – 37 735 мең сум;<br>2019 елда – 47 969,95 мең сум;<br>2020 елда – 35 585 мең сум;<br>2021 елда – 35 585 мең сум;<br>2022 елда – 35 585 мең сум»; |

«Программаны тормышка ашыруның көтелә торган соңгы нәтиҗәләре» юлының беренче абзацында «2021 елга» сүзләрен «2022 елга» сүзләренә алыштырырга;

Программаның II бүлегендәге уникенче абзацта «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2022» саннарына алыштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чаралары Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тормышка ашырыла. 2014 – 2022 елларга Программаны финанслау күләме 343 577,13 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елда – 31 487,6 мең сум;
2015 елда – 30 987,08 мең сум;
2016 елда – 32 137,9 мең сум;
2017 елда – 56 504,6 мең сум;
2018 елда – 37 735 мең сум;
2019 елда – 47 969,95 мең сум;
2020 елда – 35 585 мең сум;
2021 елда – 35 585 мең сум;
2022 елда – 35 585 мең сум.

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, Программаны тормышка ашыруга җибәрелә торган акча күләмнәре чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты проектын эшләгәндә тәгаенләнә.»;

Программаның V бүлегендәге тугызынчы абзацта «2021 елга» сүзләрен «2022 елга» сүзләренә алыштырырга;

Программага теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин